КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 июль г.Казань № 816

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 декабрь, 970 нче; 2017 ел, 28 август, 603 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 751 нче; 2020 ел, 12 март, 183 нче, 2023 ел, 17 март, 271 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренең 7 пунктында:

бишенче һәм алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин